**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ ГОРОДА ЛАИШЕВО**

422610 г.Лаишево,
ул. Коммунальная, д.3
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛАЕШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Коммунальная ур., 3 нче йорт
тел: 8-(84378) -2-50-62
факс: 8-(84378) -2-50-62

---

**2024 елның 29мае** **94 номер**

# КАРАР

## «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014елның 14 ноябрендәге 84 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 128 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре советы карарына (20.05.2015 N 101, 06.10.2015 N 10, 17.10.2018 N 111, 02.11.2018 N 112/1, 17.12.2018 N 118/1 09.10.2020 N 8, 07.11.2022 N45номер үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацны:

"Салым ташламасына хокуклы затлар салым органына ташламалар бирү турында гариза, шулай ук салым ташламасына хокукны раслый торган документлар тапшыра."

яңа редакциядә бәян итәргә:

"Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар тапшырырга хокуклы."

1.2. 3 пунктта түбәндәге эчтәлекле 3.4 пунктча өстәргә:

«3.4. Салым ташламасына хокуклы салым түләүчеләр категорияләре Россия Федерациясе Салым кодексының 407 статьясында билгеләнгән.»

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы шәһәр җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Лаеш шәһәре Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык –Лаеш муниципаль районы**
**Лаеш шәһәре Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**